ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

27 октябрь **2025 ел** **№** 1031

**2026 елга махсус Арча муниципаль районы балаларын йөртү өчен билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативларын раслау турында**

1. Расларга:

2026 елга махсус Арча муниципаль районы балаларын йөртү өчен билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативларын;

Махсус балаларны йөртү өчен билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында нигезләмәне.

2. “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының финанс-бюджет палатасы” муниципаль казна учреҗдениесына тәэмин итәргә:

гомуми белем бирү оешмаларын әлеге карарның 1 пунктында расланган махсус балаларны йөртү өчен билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары нигезендә финанслауны.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче
вазыйфаларын башкаручы И.А.Галимуллин

Расланды
Арча муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы
карары белән
«27» 10 2025 № 1031

2026 елга махсус Арча муниципаль районы балаларын йөртү өчен билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары

| Автотранспорт чарасы моделе исеме | Ике ставкалы нормативның күләме | |
|---|---|---|
| | бер автотранспорт чарасына ставка, елга сумнарда | автотранспорт чарасының бер чакрым йөрешенә ставка, елга сумнарда |
| КАВЗ | 1 177 194,49 | 28,27 |
| ПАЗ | 1 177 451,99 | 28,42 |
| ГАЗ «Газель» | 1 155 206,40 | 18,17 |
| УАЗ | 1 154 753,20 | 16,08 |
| FIAT | 1 158 244,90 | 13,29 |
| Peugeot Boxer | 1 163 580,30 | 12,88 |
| Ford Transit | 1 163 837,80 | 18,29 |
| Камаз Марко-Поло3297 | 1 179 388,39 | 25,07 |

Расланды
Арча муниципаль районы
башкарма комитеты
җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы
карары белән
«27» 10 2025 № 1031

Махсус балаларны йөртү өчен билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында
нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә махсус балаларны йөртү өчен билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү механизмын билгели (алга таба – муниципаль хезмәт).

1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативы, автотранспорт чаралары саны һәм автотранспорт чараларының хисап чорында фактта йөреп чыгу нигезендә исәпләнә.

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары ел саен Арча муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан раслана.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен формалаштырганда автотранспорт чараларының факттагы йөреше турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасында автотранспорт чараларының аерым төрләрен мониторинглауның бердәм системасы белешмәләре буенча автотранспорт чарасы маршрутының расланган паспорты кысаларында башкарылган хисап елында автотранспорт чарасының факттагы йөреше буларак кабул ителә.

2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү

2.1. i муниципаль берәмлекнең муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S_i = \sum_{m=1}^{k} (n_{f\,m} \times NF_{km_m} + NF_{as\,m} \times M_m),$$

анда:

$S_i$ – муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе;

$n_{f\,m}$ - m модельле автотранспорт чараларының фактта узуы, километрлар;

$NF_{km_m}$ - махсус балаларны йөртү өчен билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны йөртүне оештыру бәясе нормативының бер километрга ставкасы, сумнарда;

$NF_{as\,m}$ - махсус балаларны йөртү өчен билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны йөртүне оештыру бәясе нормативының бер автотранспорт чарасына ставкасы, сумнарда;

$M_m$ - m модельле автотранспорт чаралары саны, берәмлекләр;

$m$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус моделе номеры;

$k$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус модельләре саны.